РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИЗМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы, Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: lsm.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
15.09.2022

КАРАР
№51

Саба муниципаль районы Эзмә авыл
җирлеге Башкарма комитетының 06.04.2020
елның №22 карары белән расланган Саба муниципаль
районы Эзмә авыл җирлегенең салым чыгымнары
исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын
бәяләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 елгы №1081 РФ Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибенә, Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 06.04.2020 елның №22 карары белән расланган «Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм бәяләү Тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.3 пунктында «,муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 3.3 пунктның икенче абзацында «, муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3.3 пунктның өченче абзацын киләсе редакциядә бәян итергә:

«- бирелгән ташламаларны түләүчеләргә ихтыяҗ, алар ташламаларга хокуклы булган түләүчеләр санының нисбәте белән характерлана, һәм ташламаларны куллану өчен потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны яки түләүчеләрнең гомуми саны 5 ел эчендә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы. хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/izma адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Эзмә авыл
җирлеге башлыгы урынбасары Р.Г.Әхмәтов